# Шалкан (Рус халык әкияте)





Бабай шалкан утырткан. Шалкан көн үскән, төн үскән, бик зур булган.



Атналар, айлар үткән, җәй үткән, көз җиткән. Бабай шалканны йолкырга керешкән.



Тартып, тартып караган – шалкан чыкмаган. Бабай шалканны үзе генә тартып чыгара алмагач, ярдәмгә Әбине дә чакырган.



Әби – Бабайга,
Бабай шалканга
тотынган. Әй
тартканнар, әй
тартканнар —
шалкан һаман
чыкмаган. Әби
булышырга
Кызын чакырган.



Кыз – Әбигә, Әби – Бабайга, Бабай шалканга тотынган. Тартырга керешкәннәр болар. Әй тартканнар, әй тартканнар – шалкан чыкмаган. Әбинең Кызы шалканны тартышырга Акбайны чакырган.



Акбай – Кызга, Кыз – Әбигә, Әби – Бабайга, Бабай шалканга тотынган. Әй тартканнар, әй тартканнар — шалкан һаман чыкмаган, селкенмәгән дә. Акбай ярдәмгә Песине чакырып килгән.



Песи-Акбайга, Акбай – Кызга, Кыз – Әбигә, Әби – Бабайга, Бабай шалканга тотынган. Әй тартканнар, әй тартканнар — шалкан һаман чыкмаган, селкенмәгән дә. Песи ярдәмгә Тычканны чакырып килгән.



Тычкан — песигә, песи — Акбайга, Акбай — кызга, кыз — әбигә, әби — бабай-
га, бабай шалкангаябышты. Әй тарталар, әй тарталар. Җыйнаулашып тарта торгач, шалкан түзмәде — төбе-тамыры белән каерылып чыкты.